**Республика Татарстан**
**Совет Новоимянского сельского поселения Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Яңа Имән авыл җирлеге Советы**

**РЕШЕНИЕ**

**КАРАР**

16 декабрь 2022ел

№ 24

**Яңа Имән авыл җирлеге Советының 16.06.2017 ел 11нче номерлы” Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә һәм исәптән төшерүгә өметсез дип тану тәртибе турындагы” карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының " Яңа Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Яңа Имән авыл җирлеге Советының 16.06.2017 ел, № 11 «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә һәм исәптән төшерүгә өметсез дип тану тәртибе турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.1 пунктта. 1 пункт җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

- гамәлдән чыгарылган җирле салымнар (реструктуризация режимында һәм банкротлык процедураларында булган салым түләүчеләрнең бурычларыннан тыш);
- бурыч барлыкка килгән көн белән 3 елдан артык түләтеп булмый дигән акт булу;
- 01.01.2006 елга кадәр недоимка яки бурычлар булу.;
- психик авыру булып суд карары белән танылганнар затлар;
- картлар йортларында яшәүче затлар;
- иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлар;
- ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән балалар йортларында һәм приютларда тәрбияләнүче балигъ булмаганнар;
- ЕГРЮЛда мәгълүматлары булмаган юридик затлар;
- юридик затларның пенялар буенча бурычлары (недоимкага исәпләнгән), аны түләтү срогы чыкканнан соң, алар өстәлгән недоимка булмаганда.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Гараев